РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«ГОРОД ЧИСТОПОЛЬ»
ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ**
**ГОРОДСКОЙ СОВЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

**ЧИСТАЙ**
**ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ**

---

***Решение*** ***Карар***

**2021 елның 1 июле** **Чистай шәһәре** **№8/1**

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Чистай шәһәр Советы депутатының
ышанычы югалуга бәйле рәвештә
вәкаләтләрен вакытыннан алда
туктату (вазыйфадан азат итү) турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясындагы 7.1 өлеше, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13.1 статьяның 1 өлешендәге 2 пункты, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы, «Муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләрне тапшырмауга кагылышлы мәсьәләләрне карау турында» 2021 елның 10 июнендәге ПР-154 номерлы Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәш буенча эшне координацияләү комиссиясе карарыннан алынган өземтә нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Коррупциягә каршы тору турындагы законнарны бозган өчен, 2021 елның 1 июлендә ышанычны югалтуга бәйле рәвештә дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Чистай шәһәр Советы депутаты Җәббаров Рудольф Фермагел улының вәкаләтләрен (вазыйфасыннан азат итәргә) вакытыннан алда туктатырга.
2. Әлеге карар кабул ителгән вакыттан үз көченә керә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чистай шәһәренең территориаль сайлау комиссиясенә җибәрергә.
4. Әлеге карарны «Чистай хәбәрләре» газетасында яисә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында https://chistopol.tatarstan.ru урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәре башлыгы урынбасары М.И. Ксенофонтовка йөкләргә.

Чистай муниципаль районы
Чистай шәһәре башлыгы Д.А. Иванов